# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
## Әлкәй  авыл җирлеге Советы

Әлкәй авылы № 147 «23» сентябрь 2019 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Әлкәй  авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әлкәй авылында бәйрәмнәр уздыру “Җиңү көне”, “Сабантуй”, “Өлкәннәр көне”, “Яңа ел”, “Инвалидлар көне”;
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авылларында янгын ранецлары сатып алу;
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авыллары юлларын кардан чистарту;
- җәйге чорда Әлкәй, Кызыл Сукачы авыллары территорияләрен чабу;
- Әлкәй авылы Урак һәм Чүкеч урамы юлына вак таш(щебенка) җәю(сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авылларында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен төзекләндерү(чәчәк үсентеләре сатып алу);
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авылларында эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү;
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авылларында зиратларга дератизация уздыру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар  аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әлкәй авылы, Пер.Совет ур., 44а йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис: С.З.Зиннурова